**Муниципаль дәрәҗәгә декомпозацияләнгән «белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкин булуы» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының эшчәнлек регламентын раслау турында**

«2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү хакында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы указлары нигезендә Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты карар кылды:

1. Муниципаль дәрәҗәгә декомпозацияләнгән «белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан алып 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты эшчәнлегенең беркетелә торган регламентын хисап чорында расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.В. Николаевага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**